ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы вәкиллекләре эшчәнлеге турында

«Хөкүмәт сәгате» кысаларында Татарстан Республикасы вәкиллекләре эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры О.В. Коробченко мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры О.В. Коробченко мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына Татарстан Республикасы вәкиллекләре турындагы законнарны мониторинглауны дәвам итәргә.

3. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Россия Федерациясе субъектларындагы, шулай ук ерак һәм якын чит илләрдәге Татарстан Республикасы вәкиллекләре эшчәнлеген тикшереп торуны, аларның эшчәнлек нәтиҗәлелеген арттыруга, финанс-хуҗалык эшчәнлеген тикшереп торуга, матди ресурсларны, мөлкәтне һәм акчаларны максатчан һәм рациональ куллануга аеруча игътибар биреп, дәвам итүне.

3.2. Татарстан Республикасы вәкиллекләре белән сәнәгатькә инвестицияләр җәлеп итү, экспорт потенциалын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча системалы үзара хезмәттәшлекне тәэмин итүне.

3.3. Халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны, регионара хезмәттәшлекне, чит илләрдә яшәүче ватандашлар белән эшләүне гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе субъектларындагы, ерак һәм якын чит илләрдәге Татарстан Республикасы вәкиллекләре белән үзара хезмәттәшлек мәсьәләләре буенча республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итүне.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 11 июне
№ 335-VII ДС